| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯШЕЛ ҮЗӘН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 28 мае №18

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә торак урыны мәйданының хисап нормасын һәм торак урыны бирү нормасын билгеләү турында

Россия Федерациясенең Торак кодексының 50 статьясына, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. Билгеләргә:

1.1. Торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасы, шуннан чыгып, гражданнарның торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе, аларны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында, гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган торак урыны гомуми мәйданның 18 кв.м. күләмендә билгеләнә.

1.2. Социаль наем шартнамәсе буенча торак урынының гомуми мәйданын бирү нормалары:

- ялгыз яшәүче граждан өчен гомуми мәйданы 18 кв.метрдан ким булмаган торак урыны мәйданы, әмма ялгыз яшәүче граждан өчен гомуми мәйдан 33 кв.м. тәшкил итә.;
- ике кешедән торган гаилә өчен торак бинаның гомуми мәйданы 42 кв.метрдан да ким булмаган күләмдә.

2. «Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә торак урыны бирү нормасы һәм хисап нормасы турында»гы 2010 елның 1 апрелендәге 3 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы М.Г. Гатиятуллин